**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Түбән Чәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Югары Чәке авылында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**30 нчы ноябрь 2021 ел Югары Чәке авылы №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Түбән Чәке авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Югары Чәке авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы 10.10.2019 ел, № 52/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2021 елның 30 ноябрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2021 елның 30 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 53 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**35**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **66,04** % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **35** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **100%** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **0** кеше тавыш бирде, бу **0%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2021 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Түбән Чәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Югары Чәке авылында 2021 елның 30 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Югары Чәке авылының Дзержинская, Ленина урамы юл челтәрен ремонтлау.

3. 2022 елда Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Югары Чәке авылының Дзержинская, Ленина урамы юл челтәрен ремонтлау.

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Түбән Чәке авылы, Совет урамы, 11 нче йорт, МФЦ бинасы янында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы
халык җыенында рәислек итүче О.Б.Албутов